**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «31» маеннан № 232

**«Дәүләт хезмәтләренең административ регламентларын үзгәртү турында»**

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелү сәбәпле, карар бирәм:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 08 апрелендәге 172 номерлы, 2015 елның 17 августындагы 220 номерлы, 2015 елның 22 сентябрендәге 263 номерлы, 2015 елның 05 октябрендәге «Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау турында» 272 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ затларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында административ регламентка (1 нче кушымта).

1.2. Торак урыннарына мохтаҗ аерым категориядәге гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2 нче кушымта).

1.3. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм аларга тиңләштерелгән затларга радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга һәм дәүләт торак сертификатын исәпкә кую һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (3 нче кушымта).

1.4. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күченеп килергә мәҗбүр булганнарга торак сатып алуга субсидияләр бирү өчен дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (4 нче кушымта).

1.5. Торак урынны яңадан урнаштыруга һәм (яисә) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.6. Торакны торак урыны, торак урыны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).

1.7. Торак урынны торак булмаган урын һәм торак булмаган урынны торак урын итеп күчерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (9 нчы кушымта).

1.8. Торак шартларын социаль түләүләрдән файдаланып яхшырту теләгән белдергән гражданнар исемлекләренә кертү һәм авыл җирлегендә торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (68 нче кушымта).

1.9. Индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслый торган, ана (гаилә) капиталын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (69 нчы кушымта).

1.10. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү, реконструкцияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (9 нчы кушымта).

1.11. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.12. Җир эшләрен җитештерүгә ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (14 нче кушымта).

1.13. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (15 нче кушымта).

1.14. Төгәлләнмәгән төзелеш объектын куллануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (16 нчы кушымта).

1.15. Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (17 нче кушымта).

1.16. Күпфатирлы торак йортның беренче катында урнашкан фатирда балкон (лоджия) төзүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (19 нчы кушымта).

1.17. Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (20 нче кушымта).

1.18. Агачлар һәм куаклар кисүгә, ябалдашларын кисүгә һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (24 нче кушымта).

1.19. Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (25 нче кушымта).

1.20. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.21. Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта);

1.22. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган мәгълүматларны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

3. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 8 апрелендәге 172 номерлы карарының «Муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен килештерү буенча муниципаль хезмәт

күрсәтүнең административ регламенты кадастр исәбенә кую максаты белән муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 12 нче кушымтасы, «Җир кишәрлеген сайлау актын килештереп, муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 13 нче кушымтасы үз көчләрен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**